ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 ел 30 март**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 797**

Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында

Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны тәртипкә салу максатларында, 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы, Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә һәм җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын расларга(1 нче кушымта, 2 нче кушымта).
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән схема бастырып чыгарылган вакыттан бирле гамәлдә булуын билгеләргә.
3. Схеманың гамәли көче Зеленодольск шәһәре территориясендә урнаштырылган, яңа куела торган, стационар булмаган сәүдә объектларына кагыла дип билгеләргә.
4. Стационар булмаган сәүдә объектын Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруның эскиз проектына ярашлы рәвештә урнаштырырга, ул Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының баш архитекторы тарафыннан раслана.
5. Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 27 сентябрендәге «Зеленодольск шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемаларын раслау турында» 01-08-333 номерлы карарын гамәлдә түгел дип таныргa.

6. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo. tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http ://zelenodolsk. tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин